# СӘЯСӘТ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ИДАРӘ ӨЛКӘСЕ

355.Теләсә кайсы дәүләтнең билгесе булып саналган пункны күрсәтегез.

1) салым җыю хокукы

2) күппартиялелек

3) хакимият органнарына ирекле сайлаулар

4) хакимиятләрнең бүленеше

356. Сәяси партия парламент сайлауларында катнашты. Нинди өстәмә мәгълүмат, әлеге партия хакимлек итә дигән нәтиҗәгә китерәчәк?

1) Партия лидеры илнең сәяси элитасы арасында бик популяр.

2) Партия вәкилләре парламентка үтмиләр, ләкин илнең яңа хөкүмәтен һәрьяклап хуплап (ярдәм итеп) киләчәкләрен белдерделәр.

3) Партиянең лидеры, нигездә, үзенең партиясе әгъзалары кергән хөкүмәтне җитәкләде.

4) Партия үзәк гәҗит битләрендә сайлау алды агитациясен алып бару мөмкинлеген алды.

357. Җәмгыятьтә сәяси ирекнең дәрәҗәсен күрсәтеп торучы сәяси хакимиятне гамәлгә ашыру ысулын галимнәр нәрсә дип атыйлар?

1) сәяси идарә итү

2) сәяси режим

3) сәяси мөстәкыйльлек

4) сәяси статус

358. Демократик җәмгыятьтә гражданнарның сәяси тормышта катнашулары турындагы фикерләр дөресме?
А. Закон проекты буенча иҗтимагый фикер алышу гражданнарның сәяси тормышта турыдан-туры катнашу формалары булып тора.
Б. Гражданнар хөкүмәт органнарына мөрәҗәгать итеп, сәяси тормышта катнаша алалар.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

360. Җәмгыять белеме дәресендә укытучы дәүләт һәм сәяси партияләр турында сөйләде. Дәүләт һәм идарә итүче сәяси партиянең эшчәнлеген чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип номерларын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип номерларын сайлап язып куегыз.

1) гомуммәҗбүри нормалар кабул итү хокукы

2) сәяси программаларны эшкәртү

3) тулаем алганда, барлык җәмгыятьнең мәнфәгатьләрен кайгырту

4) сәяси хакимиятне гамәлгә ашыру

361. Теләсә кайсы дәүләткә хас булган билгене күрсәтегез.

1) кешенең һәм гражданның хокук һәм иреген тәэмин итүне гамәлгә ашыру
2) хакимиятнең башкарма һәм суд тармагы бүленеше
3) дәүләттә автоном берәмлекләр аерып чыгару
4) салым җыю хокукы

362. Дәүләт турындагы фикерләр дөресме?
А. Дәүләт җәмгыятьнең әхлак кыйммәтләрен билгели.
Б. Дәүләтнең бурычы – гражданнарның мәнфәгатьләрен кайгырту.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

363. Һәрбер нигезләмәсе хәреф белән билгеләнгән текстны укып чыгыгыз (А) Журнал редакциясе үз укучыларыннан: «Илдә хокукый дәүләт тудымы?» – дигән сораугa җавап алды. (Б) Укучыларның яртысыннан күбрәге тискәре җавап бирделәр. В) Мөгаен, бу – илдә кеше хокукын бозу күренешенең булуы белән бәйледер.
Текстның кайсы нигезләмәсе

1) фактларны чагылдыра

2) фикерләрне белдерә

Таблицага тиешле нигезләмәләрнең характерын белдерә торган цифрларны язып куегыз.

364. Дәүләт хакимиятенең вәкилен күрсәтегез.

1) финанс компаниясе президенты
2) иҗтимагый фонд рәисе
3) оппозицион партия лидеры
4) министрлар кабинеты башлыгы

365. Җиде елга бер тапкыр Z илендә бөтен халык тарафыннан президент сайлана. Ул хакимият башлыгы булып тора. Законнарны сайлауларда сайланып куелган парламент кабул итә. Z илендә идарә итүнең кайсы формасы урнаштырылган?

1) монархия
2) федерация
3) республика
4) демократия

366. Һәрбер нигезләмәсе хәреф белән билгеләнгән текстны укып чыгыгыз.

(А) Парламент сайлауларында җиңеп чыккан партияләр хөкүмәт оештыру һәм сәяси курс сайлау турында килешү төзеделәр. (Б) Сәяси күзәтүчеләрнең күбесе элеге килешүләрнең озак вакытка сузылуына ышанмадылар. В) Килешүнең тәкъдим ителгән варианты, гаҗәпкә каршы, озак вакытлы булып чыкты.

Текстның кайсы нигезләмәсе

1) фактларны чагылдыра
2) фикерләрне белдерә.

Таблицага тиешле нигезләмәләрнең характерын белдерә торган цифрларны язып куегыз.

367. Z дәүләтендә дәүләт башлыгы хакимиятне мирас буенча ала, законнар закон чыгару җыелышы тарафыннан кабул ителә һәм илнең хөкүмәте белән башкарыла. Z дәүләтендә идарә итүнең кайсы формасы?

1) унитар дәүләт
2) парламентар монархия
3) парламент республикасы
4) демократик дәүләт

368. Сәясәт турындагы фикерләр дөресме?

А. Сәясәт ул – дәүләт белән идарә итү сәнгате.

Б. Сәясәт ул – хакимиятләрнең гражданнарга йогынтысы.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

369. Башка хакимиятләрдән аермалы буларак, дәүләт хакимияте

1) кешеләрнең тәртибен җайга сала
2) социаль нормаларга таяна
3) үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен эшләп чыгара
4) бөтен ил халкына тарала

370. Сәяси партияләр турындагы фикерләр дөресме?
А. Сәяси партияләр закон кабул итү хокукына ия.
Б. Сәяси партияләр – максатлары хакимият өчен көрәш булган оешмалар ул.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

371. Кайсы билге теләсә кайсы дәүләтне характерлап тора?

1) парламентның булуы
2) гомуммәҗбүри законнар кабул итү
3) дәүләтнең һәм гражданнарның үзара җаваплылыгы
4) кеше хокуклары гарантиясе

373. Z илендә гражданнар югары закон чыгару хакимиятенә ия булган парламент сайлыйлар. Хөкүмәт парламент сайлауларында җиңеп чыккан партиядән формалаша. Z илендә идарә итүнең кайсы формасы?

**1)** федерация

**2)** республика

**3)** монархия

**4)** демократия

374. Һәрбер нигезләмәсе хәреф белән билгеләнгән текстны укып чыгыгыз.

(А) Кайбер политологлар демократияне кешелеклелекнең иң мөһим уңышы дип саныйлар.(Б) Демократиядә уңай якларга караганда, тискәре якларны күрүче сәясәтчеләр дә бар. В) Шулай да, нәкъ менә ул бүгенге көндә гражданнарның хокук һәм иреген тәэмин итүнең иң яхшы формасы булып тора.

Текстның кайсы нигезләмәсе

Таблицага тиешле нигезләмәләрнең характерын белдерә торган цифрларны язып куегыз.

375. Дәүләт төзелеше формасы буенча Z иле ул – унитар дәүләт. Бу нәрсәне аңлата?

**1)** Z мөстәкыйльлекнең бер өлешен тәшкил иткән берничә дәүләт берәмлекләрен берләштерә

**2)** Z иленең территориаль берәмлекләрендә үз конституцияләре кабул ителә

**3)** Z иленең территориясе административ берәмлекләргә, контроль үзәкләргә бүленә

**4)** Z илендә хөкүмәт сайлауларда җиңеп чыккан партия белән формалаша

376. Z дәүләтендә демократик, ә Y дәүләтендә тоталитар сәяси режим билгеләнгән. Бу ике сәяси режимны чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип номерларын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип номерларын сайлап язып куегыз.

| | |
|---|---|
| **1)** | иҗтимагый тәртип бозуны булдырмау |
| **2)** | башкарма хакимият органнары булу |
| **3)** | көндәшле (конкурентлы) нигездә ирекле сайлаулар |
| **4)** | судтан тыш органнар тарафыннан хөкем карары чыгарылу |

377. Балалар товарларын җитештерүчеләр хөкүмәткә үз мәнфәгатьләрен яклый торган һәм кече эшкуарлыкка ярдәм итү программасы тәкъдим иткән ассоциацияләрен булдырып теркәп куялар. Бу мисал нәрсәне күрсәтеп тора?

| | |
|---|---|
| **1)** | сайлау алды кампанияләре үткәрү |
| **2)** | муниципаль органнарның эшчәнлеге |

| | | |
|---|---|---|
| | **3)** | гражданлык җәмгыятен эшләп килүе |
| | **4)** | гражданнарның гадел хөкемдә катнашулары |

378. Һәрбер нигезләмәсе хәреф белән билгеләнгән текстны укып чыгыгыз.

(А) Z дәүләтендә периодик рәвештә парламент сайлаулары үткәрәләр, тик аларда идарә итүче партиядән генә кандидатлар тәкъдим ителгән. (Б) Массакүләм мәгълүмат чараларында бары тик хөкүмәтнең позициясе генә тәкъдим ителгән дигән шик туа. В) Мөгаен, Z илендә антидемократик режим урнаштырылгандыр.

Текстның кайсы нигезләмәсе

**1)** фактларны чагылдыра

**2)** фикерләрне белдерә.

379. Түбәндәгеләрнең кайсысы сәяси хакимияткә мисал булып килә ала?

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | троллейбус паркы белән идарә итү |
| | **2)** | хастаханә белән идарә итү |
| | **3)** | гаилә башлыгының хакимияте |
| | **4)** | өлкә губернаторының эшчәнлеге |

Таблицага тиешле нигезләмәләрнең характерын белдерә торган цифрларны язып куег

380. Теләсә кайсы дәүләткә хас булган билгене күрсәтегез.

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | гражданлык җәмгыятенең яшәеше |
| | **2)** | кешенең хокук һәм иреген хөрмәт итү |
| | **3)** | дәүләт һәм гражданнарның үзара җаваплылыгы |
| | **4)** | хокук саклау органнары булу |

381. Z дәүләте бер төркем мәсьәләләрне хәл итүдә, билгеле бер мөстәкыйльлеккә ия булган субъектларның территориясен үз эченә ала. Парламент ике палаталы структурага ия, субъектлар үзләренең махсус конституцияләрен кабул итәргә хокуклы. Китерелгән фактлар нигезендә түбәндәге нәтиҗәне ясарга була: Z ул –

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | федератив дәүләт |
| | **2)** | монархия |
| | **3)** | унитар дәүләт |

| | | |
|---|---|---|
| | **4)** | республика |

382. Сәясәт турындагы  фикерләр дөресме?
А. Хакимият өчен көрәштә үзләренең көчләрен берләштерүгә юнәлткән дәүләт органнарының, партияләрнең, иҗтимагый берләшмәләрнең эшчәнлеген сәясәт дип атыйлар.
Б. Сәясәт хакимият бүленешенә йогынты ясауга омтылышны белдерә.

**1)**  А гына дөрес

**2)** Б гына дөрес

**3)** ике фикер дә дөрес

**4)** ике фикер дә дөрес түгел

383. Һәрбер нигезләмәсе хәреф белән билгеләнгән текстны укып чыгыгыз.
(А)  Z илендә парламент сайлаулары 4 елга бер тапкыр үткәрелә.   (Б)  Сайлаучыларның берничә альтернатив кандидатлардан  үз кандидатларын ирекле төстә сайлый алулары бик мөһим. В)   Бу күренеш –  Z иленең  демократик ил булуын күрсәтеп тора дип уйларга мөмкин.
Текстның кайсы нигезләмәсе

**1)**  фактларны чагылдыра

**2)** фикерләрне белдерә.

Таблицага тиешле нигезләмәләрнең характерын белдерә торган цифрларны язып куегыз

384. Түбәндәгеләрнең кайсысы сәяси хакимиятне тормышка ашыра?

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | хөкүмәт министры |
| | **2)** | эре сәнәгать концерны башлыгы |
| | **3)** | мәктәп директоры |
| | **4)** | банк идарәсе рәисе |

385. Демократик дәүләттәге сәяси партияләр турындагы  фикерләр дөресме?
А. Сәяси партияләр  фикердәшләрне берләштерәләр.
Б. Сәяси партияләр гражданлык җәмгыятенең бер өлеше булып торалар.

**1)**  А гына дөрес

**2)** Б гына дөрес

**3)** ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

386. Хакимият бүленеше турындагы фикерләр дөресме?

А. Башкарма хакимиятне парламент барлыкка китерә.

Б. Хакимият бүленеше принцибын эзлекле рәвештә үтәү тоталитар дәүләтнең бер билгесе булып тора.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

387. Һәрбер нигезләмәсе хәреф белән билгеләнгән текстны укып чыгыгыз.

(А) Z илендә президент сайлауларының икенче турына ике дәгъва кылучы чыкты. (Б) Сайлауларның беренче турында, көтелгәнгә караганда күбрәк гражданнар катнашты. В) Икенче тур нәтиҗәләрен фаразлау, гомумән, мөмкин түгел.

Текстның кайсы нигезләмәсе

1) фактларны чагылдыра

2) фикерләрне белдерә.

Таблицага тиешле нигезләмәләрнең характерын белдерә торган цифрларны язып куегыз.

388. Референдум турындагы фикерләр дөресме?

А. Референдум барлык җәмгыятькә һәм һәрбер гражданга мөһим булган мәсьәләләр буенча бөтен халыкның тавыш бирүен күздә тота.

Б. Дәүләт хакимиятенә сайлаулардан аермалы буларак, референдум яшерен тавыш бирү юлы белән үткәрелә.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

389.Гражданнарның инициатив төркеме шәһәр җитәкчелегенең берничә урам исемен алмаштыруына каршы чыкты. Әлеге факт нәрсәнең булуы турында сөйли?

1) авторитар режим

2) гражданлык җәмгыяте

3) сәяси система

| | | |
|---|---|---|
| | **4)** | җирле үзидарә |

390. Оешма иҗтимагый проблемаларга уртак карашлары булган кешеләрне берләштерә. Ул ил белән идарә итүгә контроль ясауга ирешә һәм моның өчен дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда актив катнаша.  Бу оешма нәрсә булып тора?

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | профессиональ берләшмә |
| | **2)** | парламент  фракциясе |
| | **3)** | сәяси партия |
| | **4)** | инициатив төркем |

391. Сәяси партияләр  турындагы  фикерләр дөресме?

А.  Сәяси партияләр билгеле бер социаль төркемнең мәнфәгатьләрен кайгырталар.

Б.   Сәяси партияләр җәмгыятьнең һәм дәүләтнең үсеш программаларын эшлиләр.

**1)**  А гына дөрес

**2)** Б гына дөрес

**3)** ике фикер дә дөрес

**4)** ике фикер дә дөрес түгел

392. Демографик җәмгыятьтә гражданнарның сәяси тормышта турыдан-туры актив катнашулары турындагы  фикерләр дөресме?

А.  Сайлаулар һәм референдумнар гражданнарның сәяси тормышта   актив катнашу формалары булып торалар.

Б. Җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итеп, гражданнар  сәяси тормышта   катнаша алалар.

**1)**  А гына дөрес

**2)** Б гына дөрес

**3)** ике фикер дә дөрес

**4)** ике фикер дә дөрес түгел

393.  Сайлаулар һәм референдум турындагы  фикерләр дөресме?

А.   Демократия шартларында сайлауларда төрле сәяси көчләрнең  үз сайлаучыларының ышанычы өчен көрәшергә мөмкинлекләре бар.

Б.    Референдумда кабул ителгән карарлар Совет Федерациясе тарафыннан расланырга тиеш.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

394. Сәясәт турындагы фикерләр дөресме?
А. Сәясәт барлык гражданнарның мәнфәгатьләренә кагыла.
Б. Сәясәт хөкүмәт тарафыннан гына гамәлгә ашырыла.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

395. Җирле үзидарә турындагы фикерләр дөресме?
А. Чынлыкта, җирле үзидарә органнарына, вәкиллекле демократия белән берлектә, турыдан-туры демократия элементлары да үтеп керә.
Б. Җирле үзидарә органнары, халык мәнфәгатьләреннән чыгып, идарә итә торган территориянең үсешен тәэмин итәләр.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

396. Теләсә кайсы дәүләткә хас булган билгене күрсәтегез.

| | | |
|---|---|---|
| | 1) | дәүләтнең һәм гражданнарның үзара җаваплылыгы |
| | 2) | хакимиятнең башкарма һәм суд тармагы бүленеше |
| | 3) | дәүләттә автоном берәмлекләрнең бүленеп чыгуы |
| | 4) | хокук саклау органнары булу |

397. Сәяси партия парламент сайлауларында катнашты. Нинди өстәмә мәгълүмат әлеге партия хакимлек итә дигән нәтиҗәгә китерәчәк?

| | | |
|---|---|---|
| | 1) | Партия бер төркем сайлаучыларны үз ягына тартты, ләкин аның вәкилләре парламентка үтмәделәр. |

| | | |
|---|---|---|
| | **2)** | Партия вәкилләре парламентка үтмәделәр, ләкин илнең яңа хөкүмәтен һәрьяклап хуплап (ярдәм итеп) килүләрен белдерделәр. |
| | **3)** | Партиянең лидеры, нигездә, үзенең партиясе әгъзалары кергән хөкүмәтне җитәкләде. |
| | **4)** | Партия үзәк гәҗит битләрендә сайлау алды агитациясен алып бару мөмкинлеге алды. |

398.Хокукый дәүләтне нәрсә аерып тора?

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | дәүләт чикләре белән билгеләнгән территориясе булу |
| | **2)** | гражданнардан һәм фирмалардан салым түләтү |
| | **3)** | хакимиятнең бүленеше һәм бәйсезлеге |
| | **4)** | законлы көч куллану хокукына ия булу |

399. «Z» оешмасының әгъзалык шартларын һәм җитәкчелек органнарын, җирле бүлекчәләрен билгели торган программасы, уставы бар. Аның төп максаты – дәүләт хакимиятен яулап алу. Әлеге иҗтимагый берләшмә нәрсә булып тора?

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | профессиональ берләшмә |
| | **2)** | сәяси партия |
| | **3)** | иҗтимагый хәрәкәт |
| | **4)** | акционерлык җәмгыяте |

400. Z дәүләтендә демократик, ә Y дәүләтендә тоталитар сәяси режим билгеләнгән. Бу ике сәяси режимны чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип номерларын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип номерларын сайлап язып куегыз.

**1)** конкурентлы нигездә ирекле сайлаулар

**2)** иҗтимагый тәртип бозуны булдырмау

**3)** башкарма хакимият органнары булу

**4)** алга киткән гражданлык җәмгыяте

401. Демократик режимның аерылып тора торган билгесен күрсәтегез.

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | законнар системасы булу |
| | **2)** | парламент катнашыннан тыш законнарны эшкәртү һәм кабул итү |

| | | |
|---|---|---|
| | **3)** | суд системасы эше |
| | **4)** | идеологик төрлелек |

402. Хокукый дәүләтне нәрсә аерып тора?

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | хакимиянең бүленеше һәм бәйсезлеге |
| | **2)** | законнар булдыру |
| | **3)** | тышкы сәясәтнең бәйсезлеге |
| | **4)** | парламент булу |

403. Китерелгән билгеләмәләрнең кайсысы, барыннан да элек, “хокукый дәүләт” төшенчәсенә карый?

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | законнар кабул итеlә, салымнар һәм пошлина җыела торган дәүләт |
| | **2)** | хакимият бүленеше принциплары, шәхес һәм дәүләтнең үзара җаваплылыгы тормышка ашырылган дәүләт |
| | **3)** | бәйсез тышкы сәясәт алып бара, тышкы сәүдәне үстерә торган дәүләт |
| | **4)** | идарә профессиональ түрәләр тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт |

404. Z дәүләдәтендә парламент халык тарафыннан сайлана. Нинди өстәмә мәгълүмат Z дәүләтендә демократик режим урнаштырылуы турында нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирәчәк?

**1)** Z илендә республика идарә формасы.

**2)** Гражданнарның хокуклары һәм ирекләре закон тарафыннан гарантияләнә.

**3)** Z иле өязләргә бүленгән.

**4)** Z илендә бер партияле система урнашкан.

405. Билге һәм сәяси оешмалар арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: беренче баганада бирелгән һәрбер элементка икенче баганадан туры килә торган элемент сайлап алыгыз.

**БИЛГЕЛӘР** **СӘЯСИ ОЕШМАЛАР**

| | | | |
|---|---|---|---|
| **А)** | аерым бер социаль төркемнәрнең мәнфәгатьләрен кайгырту | **1)** | дәүләт |
| **Б)** | җирле закон чыгару җыеннарына депутатлар сайлауда катнашу | **2)** | сәяси партия |
| **В)** | гомуммәҗбүри хокук нормаларын чыгару | | |
| **Г)** | хокук саклау органнарын булдыру | | |
| **Д)** | салымнар билгеләү | | |

406. Гражданлык җәмгыяте турындагы фикерләр дөресме?
А. Гражданлык җәмгыяте күпсанлы инициатив берләшмәләр һәм гражданнарның оешмаларын берләштерә.
Б. Алга киткән гражданлык җәмгыяте - демократия күренешләренең берсе.

**1)** А гына дөрес

**2)** Б гына дөрес

**3)** ике фикер дә дөрес

**4)** ике фикер дә дөрес түгел

407. Демократик сәяси режим билгесен (-ләрен) күрсәтегез.

**1)** хакимиятнең бер җитәкче кулында гына булуы

**2)** бер партиянең идеологиясе өстенлек итү

**3)** парламентның президентка буйсынуы

**4)** дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар конкурентлы нигездә булу

408. Һәрбер нигезләмәсе хәреф белән билгеләнгән текстны укып чыгыгыз.
(А) Ике дәгъва кылучы президент сайлауларының икенче турына чыкты. Б) Кандидатларның сайлау алды рейтинглары тигезләште. В) Һичшиксез, тавыш бирүнең икенче тур нәтиҗәләрен алдан фаразлау мөмкин түгел.
Текстның кайсы нигезләмәсе

| | |
|---|---|
| **1)** | фактларны чагылдыра |
| **2)** | фикерләрне белдерә. |

Таблицага тиешле нигезләмәләрнең характерын белдерә торган цифрларны язып куегыз.

409. Җирле үзидарә органнары, законга яраклы рәвештә, түбәндәгеләрне гамәлгә ашыралар.

**1)** тышкы сәяси карарларны кабул итү һәм тормышка ашыру

**2)** билгеле бер территориягә караган халыкны төрле хезмәтләр белән тәэмин итү

**3)** федераль милек объектлары белән идарә итү

**4)** федераль салым җыю һәм аларны бюджетка күчерү

410. Демократик сайлаулар турындагы фикерләр дөресме?

А. Гражданнарга берничә кандидат арасыннан сайларга мөмкинлек бар.

Б. Сайлауга бер көн кала сайлау алды агитациясенә тыю куела.

**1)** А гына дөрес

**2)** Б гына дөрес

**3)** ике фикер дә дөрес

**4)** ике фикер дә дөрес түгел

411. Референдум сайлаулардан нәрсәсе белән аерыла?

**1)** яшерен тавыш бирү

**2)** куелган мәсьәлә белән риза булу (булмау)

**3)** балигъ булган гражданнарның катнашуы

**4)** ирекле катнашу

412. Сәяси хакимиятне гамәлгә ашыручыны күрсәтегез.

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | университет ректоры |
| | **2)** | хакимият башлыгы |
| | **3)** | завод директоры |
| | **4)** | кораллы көчләр офицеры |

404. Демократик җәмгыятьтә сәяси партияләр турындагы фикерләр дөресме?

А. Демократик җәмгыятьтә сәяси партияләр җәмгыятьнең үсеше турында программалар эшлиләр һәм аларны пропагандалыйлар.

Б. Демократик җәмгыятьтә сәяси партияләр салымнарның һәм җыемнарның күләмен билгелиләр, законнар әзерлиләр.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

405. Дәүләт-территориаль корылышның билгеләре һәм формалары арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: беренче баганада бирелгән һәрбер элементка икенче баганадан туры килә торган элемент сайлап алыгыз.

| **БИЛГЕЛӘР** | **Дәүләт-терориториаль корылыш формалары** |
|---|---|
| **А)** җирле идарә органнары бары тик үзәк хакимият тарафыннан гына контрольдә тотыла | **1)** федератив дәүләт |
| **Б)** чагыштырмача сәяси мөстәкыйльлеккә ия булган субъектлар берләшәләр | **2)** унитар дәүләт |
| **В)** парламент ике палата хасил итә | |
| **Г)** административ-территориаль берәмлекләр автономиясе җирле үзидарә кысаларында яшәп киләләр | |
| **Д)** административ-территориаль берәмлекләрнең үз конституцияләре була | |

Сайланган цифрларны тиешле хәрефләр астына таблицага язып куегыз.

406. Гражданлык җәмгыяте турындагы фикерләр дөресме?
А. Гражданлык җәмгыяте кешеләрнең төрле өлкәләргә караган шәхси мәнфәгатьләрен белдерә.
Б. Гражданлык җәмгыятенең фундаментын милек формаларының төрлелегенә нигезләнгән базар икътисады алып тора.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

407. Сәясәт турындагы фикерләр дөресме?

А. Дәүләт органнарының, партияләрнең, иҗтимагый берләшмәләрнең хакимият өчен көрәштә көчләрен берләштерүгә юнәлткән эшчәнлеген сәясәт дип атыйлар.

Б. Сәясәт дигәндә җәмгыятьнең әхлак нормаларын бозучыларга тәэсир итү ысулын аңларга кирәк.

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | А гына дөрес |
| | **2)** | Б гына дөрес |
| | **3)** | ике фикер дә дөрес |
| | **4)** | ике фикер дә дөрес түгел |

408. Дәүләтнең аерылып тора торган билгесе -

**1)** башка илләр белән сату-алу эшчәнлеге

**2)** сәяси лидерның булуы

**3)** закон чыгару хокукы булу

**4)** бердәм гомуммәҗбүри идеология булу

409. Z иле парламенты ике палаталы структурага ия, субъектлар үз конституцияләрен кабул итәргә хокуклы. Z иленең дәүләт-территориаль корылышының формасы нинди?

**1)** парламент республикасы

**2)** конституцион монархия

**3)** унитар дәүләт

**4)** федератив дәүләт

410. Китерелгән билгеләрнең кайсысы демократик хокукый дәүләтне аерып тора?

**1)** контрактлы нигездә формалаша торган армиянең булуы

**2)** кешенең хокук һәм иреге законнар белән гарантияләнәнүе

**3)** илдә сәяси партиянең эшчәнлеген җайга сала торган законның булуы

**4)** президент каршында илнең әйдәп баручы партияләрнең лидерларыннан консультатив киңәш (совет) булдыру

411. Түбәндә китерелгән фактларның кайсысы Z илендә демократик сәяси режим урнаштырылуын дәлилләп тора?

1) Илнең балигъ булган барлык гражданнары парламентка сайлауларда катнашу хокукына ия.

2) Хакимият өчен көрәштә сәяси партияләр бер-берсе белән иркен конкурентка керәләр.

3) Парламентның югары палатасын төбәк вәкилләре формалаштыралар.

4) Сайлау участокларында полиция хезмәткәрләре кизү (дежур) торалар.

412. Сәяси партияләр турындагы фикерләр дөресме?
А. Сәяси партияләр билгеле бер сәяси идея тарафдарларын берләштерәләр.
Б. Партия эшчәнлеге гражданнарны сәясәттә катнашуга җәлеп итүгә юнәлтелә.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

413. Билге һәм сәяси оешмалар арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: беренче баганада бирелгән һәрбер элементка икенче баганадан туры килә торган элемент сайлап алыгыз.

| **БИЛГЕЛӘР** | **СӘЯСИ ОЕШМАЛАР** |
|---|---|
| **А)** законнар чыгару | **1)** дәүләт |
| **Б)** салым җыю хокукы | **2)** парпартия |
| **В)** сайлау кампанияләре нәтиҗәләре буенча хакимият алуга омтылу | |
| **Г)** кораллы көчләр булдыру | |
| **Д)** җәмгыятьнең билгеле бер төркеменең мәнфәгатьләрен тәкъдим итү | |

Сайланган цифрларны таблицага тиешле хәрефләр астына язып куегыз.

414. Гражданнарның сәясәттә катнашулары турындагы фикерләр дөресме?
А. Сәяси партияләр билгеле бер сәяси идеяләр тарафдарларын берләштерәләр.
Б. Партия эшчәнлеге гражданнарны сәясәттә катнашуга җәлеп итүгә юнәлтелә.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

415. РФ гражданнарының сәяси катнашу формалары буларак, сайлауларга һәм референдумга нәрсә хас?

1) үткәрүнең кабатлануы закон белән билгеләнә
2) РФ Президенты посты кандидатына тавыш бирү
3) бер гражданин бер тавышка ия
4) нинди дә булса карарны хуплау яки хупламау

416. Z илендә дәүләт башлыгы хакимиятне мирас нигезендә ала, законнар закон чыгару җыелышы тарафыннан кабул ителә һәм илнең хөкүмәте тарафыннан үтәлә. Z дәүләтенең идарә итү формасы нинди?

1) унитар дәүләт
2) парламентар монархия
3) парламент республикасы
4) абсолют монархия

417. Гражданнарның сәясәттә катнашулары турындагы фикерләр дөресме?

А. Гражданнар сайлаулар һәм референдумнар аша сәяси тормышта катнашалар.

Б. Гражданнар, үзләренең мөрәҗәгатьләрен дәүләт хакимиятенә юнәлтеп, сәяси тормышта катнашалар.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

418. Түбәндә китерелгәннәрнең кайсысы гражданлык җәмгыятенең эшчәнлегенә карый?

1) район халкының автозаправка төзелешенә каршы митингы
2) парламент тарафыннан закон кабул итү
3) дәүләт җитәкчесенең хөкүмәт алдында чыгыш ясавы

**4)** ике дәүләтнең дуслык һәм сәүдә турында күлешү төзүе

419. Сәяси режимның билге һәм төрләре арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: беренче баганада бирелгән һәрбер элементка икенче баганадан туры килә торган элемент сайлап алыгыз.

| **БИЛГЕЛӘР** | **СӘЯСИ РЕЖИМ ТӨРЛӘРЕ** |
|---|---|
| **А)** дәүләт хөкүмәтенә ирекле сайлаулар | **1)** демократик |
| **Б)** хокукый дәүләт | **2)** тоталитар |
| **В)** мәҗбүри булган дәүләт идеологиясе | |
| **Г)** кеше тормышының һәм җәмгыятьнең бөтенесен эченә алган даими контроле | |
| **Д)** күппартияле система | |

Сайланган цифрларны таблицага тиешле хәрефләр астына язып куегыз.

421. Z дәүләтендә барлык гражданнар да закон алдында тигез, дин иреге принцибы эшли, мәҗбүри булган дәүләт идеологиясе юк. Z илендә кайсы сәяси режим урнаштырылган?

**1)** авторитар

**2)** тоталитар

**3)** диктаторлык

**4)** демократик

422. Тоталитар режимны нәрсә аерып тора?

**1)** дәүләт аппартының булуы

**2)** гражданнарның хокук һәм ирек гарантиясе

**3)** ирекле матбугат эшчәнлеге

**4)** дәүләтнең җәмгыять тормышында төрле яклы контроле

423. Сәясәт турындагы фикерләр дөресме?

А. Сәясәт дәүләт эшләрендә катнашу белән бәйләнгән.

Б. Сәясәт ул – хакимият уңаеннан зур иҗтимагый төркемнәр арасындагы мөнәсәбәтләр белән бәйләнгән эшчәнлеге.

**1)** А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

424. Һәрбер нигезләмәсе хәреф белән билгеләнгән текстны укып чыгыгыз.
(А) Россиядә дистәләгән сәяси партияләр һәм хәрәкәтләр бар. Б) Сәяси партиянең уңышы күп вакытта аның җәмгыятьнең алышынып торган ихтыяҗларын кабул итәргә сәләтле булуына бәйлелеген искә алырга кирәк. В) (В) Сәясәт эшлеклеләре беркайчан да потенциаль сайлаучыларны җәлеп итү турында онытырга тиеш түгелләр.
Текстның кайсы нигезләмәсе

1) фактларны чагылдыра

2) фикерләрне белдерә.

---

Таблицага тиешле нигезләмәләрнең характерын белдерә торган цифрларны язып куегыз.

425. Максаты – парламент сайлауларында җиңеп чыгу булган Z оешмасы, эшмәкәрлеккә ярдәм итеп, урта сыйныфның мәнфәгатьләрен белдерә. Z оешмасы кайсы типка карый?

1) дәүләт аппараты

2) профессиональ берләшмә

3) сәяси партия

4) иҗтимагый оешма

426. Дәүләт турындагы фикерләр дөресме?
А. Башка сәяси оешмалардан аермалы буларак, дәүләт сәяси лидерлар чыгара.
Б. Теләсә кайсы дәүләт җәмгыятьнең стабильлеген тәэмин итү максатыннан законнар кабул итә һәм әзерли.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

427. Дәүләт турындагы фикерләр дөресме?

А.  Дәүләт илдә ачык хакимиятне гамәлгә ашыра.
Б.  Дәүләт  гражданнардан һәм фирмалардан салымнар һәм җыемнар  түләтү хокукына ия.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

428. Z оешмасының  программа һәм уставы бар. Ул төбәк оешмалары челтәре  һәм яшьләр бүлекчәсенә ия.  Аның төп максаты – дәүләт хакимиятендә катнашу. Әлеге иҗтимагый берләшмә нәрсә булып тора?

1) профессиональ берләшмә
2) сәяси партия
3) иҗтимагый хәрәкәт
4) акционерлык җәмгыяте

429. Сәяси партияләр  турындагы  фикерләр дөресме?
А. Партияләр җәмгыять һәм хакимият арасында бәйләп торучы чылбыр булып торалар.
Б. Шактый күп сандагы дәүләт лидерлары өчен сәяси партиядә әгъзалык  аларның сәяси карьераларында башлангыч пункт булды.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

430. Хокукый дәүләт  турындагы  фикерләр дөресме?
А.  Хокукый дәүләт өчен алга киткән гражданлык җәмгыятенең булуы зарур.
Б.  Закончылыкның тармакланып киткән челтәре - хокукый дәүләтнең аерылып тора торган билгесе булып  тора.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

431. Барлык хакимиятнең бер генә кулда яки сәяси хакимият органында булу һәм башка институтларның роле кимү белән характерланучы сәяси режим нәрсә була?

1) революцион
2) авторитар
3) либераль
4) демократик

432. Демократик режим турындагы фикерләр дөресме?
А. Демократик режим кеше хокукын һәм иреген тануга нигезләнә.
Б. Демократик режим вакытында периодик рәвештә дәүләт хакимиятенә ирекле сайлаулар үткәрелә.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

433. Z илендә хакимият, гражданнарның хокукларын чикләгән һәм аларның шәхси тормышларын тулысынча контрольгә тотарга омтылган бер сәяси партиягә карый. Парламентка даими сайлауларга карамастан, ул бу партия әгъзаларыннан гына формалаша. Илдә бер сәяси идеология хакимлек итә. Z иленең сәяси режимы нинди?

1) демократик
2) федератив
3) тоталитар
4) монархик

434. «Монархия» һәм «республика» төшенчәләре нәрсәне характерлый?

1) идарә итү формасын
2) дәүләт-территориаль төзелешне
3) сәяси режимны
4) административ бүленешне

435. Дәүләт турындагы  фикерләр дөресме?
А.  Салым түләтү  - дәүләтнең бер билгесе булып тора.
Б.  Бары унитар дәүләтләр генә мөстәкыйльлеккә ия.

